РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 сентябрь г.Бугульма № 969

**Бөгелмә муниципаль районы территориясеннән авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләрен, бәйләү аэростатларын күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Бөгелмә муниципаль районы территориясеннән авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләрен, бәйләү аэростатларын күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетының мәгълүмат технологияләре бүлегенә, әлеге карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне дәвамында, аны Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы рәсми сайтының “Интернет” челтәренә урнаштырырга.
3. Әлеге карарны тормышка ашыруда контрольне Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад сораулары буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы В.В.Гарәфетдинов